**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
ЧЕРЕМШАНСКИЙ
МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН
**СОВЕТ**
**СТАРОКУТУШСКОГО**
**СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ**

Свежухина, дом34, с.Старые Кутуши, 423116

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
ЧИРМЕШӘН МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ
**ИСКЕ КӨТЫШ АВЫЛ**
**ҖИРЛЕГЕ**
**СОВЕТЫ**
урамы,34 йорт, иске котыш авыл, 423116

**№134** **17.06.2019 ел**

**Татарстан Республикасы**
**Чирмешән муниципаль районы**
**Иске Котыш авыл җирлеге советы утырышы**

## КАРАРЫ

Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Иске Котыш авыл җирлеге Советының 2017 елның 9 мартында кабул ителгән 44 номерлы «Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Иске Котыш авыл җирлеге муниципаль хезмәткәрләренә тиешле еллар эшләгән өчен пенсиягә чыгу белән бәйле рәвештә бер тапкыр бирелә торган акчалата түләү тәртибе турындагы нигезләмәне раслау хакында " карарына үзгәрешләр кертү турында

2007 елның 2 мартында кабул ителгән 25-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» гы, 2013 елның 28 декабрендә кабул ителгән 400-ФЗ номерлы «Иминият пенсияләре турында» гы, Татарстан Республикасы Муниципаль хезмәт турындагы кодексы, Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Иске Котыш авыл җирлеге Уставы белән яраштырып, Чирмешән муниципаль районы Иске Котыш авыл җирлеге Советы КАРАР ИТТЕ:

1. Чирмешән муниципаль районы Иске Котыш авыл җирлеге муниципаль хезмәткәрләренә тиешле еллар эшләгән өчен пенсиягә чыгу сәбәпле бер тапкыр бирелә торган акчалата бүләкне түләү тәртибе турындагы нигезләмәгә кертергә. Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Иске Котыш авыл җирлеге Советының 2017 елның 9 мартындагы 44 номерлы карары белән расланган карары белән түбәндәге үзгәрешләр кертелде:

1.1. Нигезләмәнең 3 пунктын яңа редакциядә бәян итәргә: "3. Тиешле еллар эшләгән өчен пенсиягә чыгу дигәндә, картлык буенча хезмәт пенсиясен алу хокукы бирә торган яшькә җиткәннән соң яки «Россия Федерациясендә иминият пенсияләре турында» 28.12.2013 ел, № 400-ФЗ Федераль закон нигезендә инвалидлык буенча пенсия билгеләгәннән соң, муниципаль хезмәткәрнең гаепле гамәлләренә бәйле эштән азат ителүеннән тыш, муниципаль хезмәттән азат ителү аңлашыла.

2. Әлеге карарны pravo.tatarstan.ru рәсми хокукый порталында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районының рәсми сайтында Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга тиеш.

Башлык,
Иске Котыш авыл җирлеге Советы рәисе А. К. Митякин